ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.03.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 819**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында» 2019 елның 23 декабрендәге 2835 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   - 4.4 п.«Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында ((http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырырга.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин